**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы**

**мәгариф һәм фән**

**министры**

**___________ И.Г.Һадиуллин**

**«___» _________ 2022 нче ел**

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән бердәм республика имтиханын уздыру өчен күрсәтмә материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

**1. Имтихан эше билгеләнеше**

Бердәм республика имтиханы, стандартлаштырылган биремнәр кулланып, урта гомуми белем бирү дәүләт программаларын үзләштергән укучыларның әзерлек сыйфатын объектив бәяләүне күздә тота.

Татар теленнән бердәм республика имтиханнары нәтиҗәсе гомуми белем бирү оешмаларында дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буларак билгеләнә.

**2. Имтихан эшенең эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге түбәндәге документларга нигезләнеп билгеләнә:

1. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Җамалетдинов Р.Р. һ.б. Урта гомуми белем бирүче мәктәпләр өчен татар теленнән программа (1-11нче сыйныфлар). – Казан: Мәгариф, 2010.
2. Галиуллина Г.Р., Шәкүрова М.М. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (10 – 11 нче сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263448.docx

**3. Имтихан эшенең төзелеше**

Укучыга татар теле фәне буенча имтихан эшендә тәкъдим ителгән 4 җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган – 30 бирем, кыска җавап бирүне таләп иткән – 8 һәм киңәйтелгән җавап (язма текст) бирүне таләп иткән ачык типтагы 1 бирем тәкъдим ителә.

Татар теленнән имтихан эше өч өлештән гыйбарәт.

1 нче өлеш – (1–30) җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр.

2 нче өлеш (31 –38) – кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр. Бу өлештә тәкъдим ителгән биремнәр укучының текстны анализлый белү осталыгын тикшерүгә юнәлдерелгән.

3 нче өлеш (39) – укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы бирем.

Имтихан эшендә биремнәрнең чагылышы алдагы таблицада бирелә.

***Биремнәрнең имтихан эшендә чагылышы***

| **Эшнең өлешләре** | **Биремнәрнең саны** | **Башлангыч (максималь) иң югары балл** | **64 баллга тигез барлык эшнең иң югары башлангыч баллдан биремнәрнең әлеге кисәге өчен куелган иң югары башлангыч баллның проценты** | **Биремнәрнең төрләре (типлары)** |
|---|---|---|---|---|
| 1 нче өлеш | 30 | 30 | 47 % | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр |
| 2 нче өлеш | 8 | 11 | 17% | Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр |
| 3 нче өлеш | 1 | 23 | 36% | Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәр |
| Барлыгы | 39 | 64 | (100%) | |

**4. Имтихан эше биремнәрен эчтәлекләре һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү**

Әлеге бүленеш алдагы таблицада күрсәтелә.

***“Татар теле” фәненең төп бүлекләре буенча биремнәр бүленеше***

| **Бүлекләр** | **Бирем нәр саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **60 баллга тигез булган иң югары башлангыч баллдан биремнәрнең әлеге кисәге өчен куела торган иң югары башлангыч балл проценты** |
|---|---|---|---|
| Фонетика | 2 | 2 | 3,1% |
| Лексика һәм фразеология | 2 | 2 | 3,1 % |
| Сүз ясалышы | 2 | 2 | 3,1 % |
| Морфология | 3 | 3 | 4,8 % |
| Синтаксис | 6 | 6 | 9,4 % |
| Орфография | 7 | 7 | 10,9 % |
| Пунктуация | 7 | 7 | 10,9 % |
| Сөйләм. Тәрҗемә | 6 | 6 | 9,4% |
| Сөйләм. Тел нормалары | 2 | 2 | 3,1 % |
| Татар сөйләменең матурлыгы. | 1 | 4 | 6,3 % |
| Сөйләм үстерү. Сочинение | 1 | 23 | 35,9 % |
| *Барлыгы* | 39 | 64 | 100 % |

Татар теленнән имтихан тесты биремнәре тел материалын бирү ысуллары ягыннан бик төрле. Укучы сүзләр, сүзтезмәләр яки җөмләләр буларак тәкъдим ителгән тел материалы, текст эчендә кулланылган тел күренешләре белән эш итә, башлангыч текстта күтәрелгән проблемага, тасвирланган вакыйгага карата үз фикерен белдерә.

***Тест биремнәренең тел материалы белән эшләү төрләре ягыннан бүленеше***

| **Тел материалы белән эшләү төрләре** | **Биремнәр саны** | **Иң югары башлан-гыч балл** | **64 баллга тигез булган иң югары башлангыч баллдан чыгарылган тел материалы белән эшләүнең төрләрен чагылдыра торган биремнәрне үтәгән өчен куелган иң югары балл проценты** |
|---|---|---|---|
| Сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр рәвешендә тәкъдим ителгән тел материалы белән эшләү | 21 (1– 5, 12-27) | 21 | 33 % |
| Текстта чагылыш тапкан тел материаллары белән эшләү | 17 (6-11, 28-30, 31–38) | 20 | 31 % |
| Тәкъдим ителгән башлангыч текстка нигезләнеп, язма рәвештә үз фикереңне белдерү | 1 (39) | 23 | 36 % |
| *Барлыгы* | 39 | 64 | 100% |

**5. Имтихан эше биремнәрен катлаулылыгы дәрәҗәсеннән чыгып бүлү**

Имтихан эшенең беренче бүлеге (1–30) чыгарылыш сыйныф укучыларының база материалын үзләштерү дәрәҗәләрен тикшерүгә юнәлдерелгән.

Икенче бүлеккә караган барлык биремнәр (31–38) нигез (база) материалдан катлаулырак саналалар.

39 бирем иң катлаулы санала.

***Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше***

| **Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе** | **Биремнәрнең саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **64 баллы иң югары башлангыч баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге кисәге өчен куелган иң югары башлангыч балл проценты** |
|---|---|---|---|
| Нигез (база) | 30 | 30 | 47 % |
| Катлауландырылган | 8 | 11 | 17 % |
| Югары | 1 | 23 | 36 % |
| Барлыгы | 39 | 64 | 100 % |

Имтихан эшенә тәкъдим ителгән тестларның вариантлары катлаулылык дәрәҗәсе буенча да, төзелеше буенча да бер төрле булып, биремнәр дә бер үк тәртиптә бирелә.

**6. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы**

1 һәм 2 нче өлештәге һәр дөрес үтәлгән биремнәр (38 нче биремнән кала) өчен 1 балл куела. Дөрес җавап яки җавап бөтенләй булмаса, 0 балл куела.

38 биреме 0 – 4 балл арасында бәяләнә. Дөрес билгеләнгән һәр сан өчен 1 балл куела (4 балл: хаталар юк; 3 балл: 1 хата бар; 2 балл: 2 хата бар; 1 балл – бер генә сан дөрес күрсәтелгән; 0 балл: тулысынча хата җавап (саннарның дөрес булмаган җыелмасы) яки аларның язылмавы). Җавапта саннарны язу тәртибе мөһим.

Имтихан эшенең 3 нче өлешен уңышлы башкарган укучыга куела торган иң югары балл – 23.

Имтихан эшенең барлык биремнәрен эшләү нәтиҗәләре нигезендә укучыга куела торган иң югары балл – 64.

Имтихан эшенең барлык биремнәрен эшләү нәтиҗәләре нигезендә 100 баллы шкалада югары һәм урта һөнәри белем бирү йортларына керү мөмкинлеге бирә торган тест баллары билгеләнә.

**7. Эшне башкару вакыты**

Имтихан эшен үтәү өчен, 210 минут вакыт бирелә.

Имтихан эшенең беренче өлеше җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган 30 биремнән гыйбарәт. Бу бүлектәге 1 биремне үтәү өчен, 1-3 минут вакыт бирелә, ягъни укучы аларны якынча 60 минут эчендә үтәргә тиеш була.

Икенче өлеш 8 биремнән тора. Андагы һәр биремне үтәү өчен, 3-7 минут таләп ителә. Димәк, бу өлеш якынча 30 минут эчендә эшләнергә тиеш.

Өченче өлештәге язманы, бирелгән текстка нигезләнеп һәм үз фикереңне белдереп, 120 минут эчендә башкарырга кирәк.

**8. Имтихан эшенең планы**

Татар теленнән имтихан эше вариантларын формалаштыру өчен, имтихан эшенең гомумиләштерелгән планы эшләнгән. Ул кушымтада бирелә.

**9. 2023 нче елгы бердәм республика имтиханы контроль үлчәү материалларында үзгәрешләр**

Эшнең барлык төп характеристикаларында үзгәрешләр юк.

Укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын билгеләүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнең тикшерү һәм бәяләү критерийлары тәгаенләнгән.

## 2023 нче елда татар теле буенча уздырылачак бердәм республика имтиханы контроль бәяләү материалларының гомумиләштерелгән планы

*Эштә һәм җавап бланкларында биремнәрне билгеләү: 1-30 - җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, 31-38 - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр, 39 - укылган текст нигезендә үз фикерен белдерә алуын тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнәр.*

*Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе: Н – нигез (база), К – катлауландырылган, Ю – югары.*

| **Биремнең эштәге билгеләнеше** | **Эчтәлекнең тикшерелә торган элементлары** | **Эчтәлекнең тикшерелә торган элементларының коды (кодификаторның 1 нче п.)** | **Тикшерелә торган күнекмәләр коды (кодификаторның 2 нче п.)** | **Биремнәрнең авырлык дәрәҗәсе** | **Эшләнгән бирем өчен куелган иң югары балл** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сөйләм. Тел нормалары. Орфоэпик нормалар | 9.1 | 2 | Н | 1 |
| 2 | Лексика. Кулланылышы һәм килеп чыгышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы | 2.4 | 3 | Н | 1 |
| 3 | Лексика. Омонимнар. Антонимнар. Синонимнар | 2.2 | 3 | Н | 1 |
| 4 | Сүз ясалу ысуллары | 3.2 | 15 | Н | 1 |
| 5 | Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү | 8.3 | 6 | Н | 1 |
| 6 | Сөйләм культурасы һәм тәрҗемә | 8.1 | 13 | Н | 1 |
| 7 | Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү | 8.2 | 6 | Н | 1 |
| 8 | Сүз ясалышын тикшерү | 3.3 | 3 | Н | 1 |
| 9 | Татар сөйләменең матурлыгы. Стильләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләре | 8.5 | 14 | Н | 1 |
| 10 | Синтаксис. Кушма җөмләгә синтаксик анализ | 5.14 | 17 | Н | 1 |
| 11 | Пунктуация. Аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләдә тыныш билгеләре | 7.13 | 11 | Н | 1 |
| 12 | Пунктуация. Аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләдә тыныш билгеләре | 7.5 | 11 | Н | 1 |
| 13 | Орфография | 6 | 17 | Н | 1 |
| 14 | Пунктуация. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре | 7.6 | 17 | Н | 1 |
| 15 | Синтаксис. Иярчен кисәкләр | 5.3 | 17 | Н | 1 |
| 16 | Синтаксис. Сүзтезмә | 5.1 | 16 | Н | 1 |
| 17 | Орфография. о-ы, ө-е хәрефләренең | 6.2 | 10 | Н | 1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | дөрес язылышы | | | | |
| 18 | Орфография. Алынма сүзләрнең дөрес язылышы | 6 | 10 | Н | 1 |
| 19 | Орфография. Тезмә, парлы, кушма сүзләрнең дөрес язылышы | 6.15 | 10 | Н | 1 |
| 20 | Фонетика. Сүзгә фонетик анализ | 1.2 | 9 | Н | 1 |
| 21 | Орфография. Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләре | 6.9 | 9 | Н | 1 |
| 22 | Сүзнең ясалышын тикшерү | 3.3 | 17 | Н | 1 |
| 23 | Орфография. Кушма сүзләрнең дөрес язылышы | 6.15 | 10 | Н | 1 |
| 24 | Пунктуация. Аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләдә тыныш билгеләре | 7.13 | 11 | Н | 1 |
| 25 | Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү | 8.3 | 6 | Н | 1 |
| 26 | Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү | 8.2 | 6 | Н | 1 |
| 27 | Орфография. ъ-ь билгеләрнең дөрес язылышы | 6.4 | 10 | Н | 1 |
| 28 | Орфография. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы | 6.14 | 10 | Н | 1 |
| 29 | Пунктуация. Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре | 7.5 | 10 | Н | 1 |
| 30 | Синтаксис. Гади җөмләгә синтаксик анализ | 5.13 | 17 | Н | 1 |
| 31 | Морфология. Мөстәкыйль сүз төркемнәре | 4.1 | 4 | К | 1 |
| 32 | Морфология. Мөстәкыйль сүз төркемнәре | 4.1 | 4 | К | 1 |
| 33 | Пунктуация. Гади җөмләдә тыныш билгеләре | 7.2 | 10 | К | 1 |
| 34 | Сөйләм. Тел нормалары. Орфоэпик нормалар | 9.1 | 2 | Н | 1 |
| 35 | Синтаксис. Иярченле кушма җөмлә. | 5.10 | 10 | Н | 1 |
| 36 | Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү | 8.3 | 6 | Н | 1 |
| 37 | Синтаксис. Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр | 5.4 | 17 | К | 1 |
| 38 | Морфология. Мөстәкыйль сүз төркемнәре | 4.1 | 4 | К | 4 |
| 39 | Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү | 8.6 | 18<br>19<br>20<br>21 | Ю | 23 |